| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.01.2019 Баулы № 100

Баулы шәһәр Советының
«Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге Уставын кабул
итү турында» карар
проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы шәһәр Советы Карары проектын (1нче кушымта) хупларга һәм фикер алышуга, шул исәптән ачык тыңлауларга чыгарырга.

2. Карар проектын 1нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.

3. Расларга:

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашуы тәртибен (2нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен (3нче кушымта).

4. Түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы http//pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга:

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы шәһәр Советы карары проектын (1нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашуы тәртибен (2нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен (3нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына карата кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм тикшерү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1. Тимофеев Станислав Николаевич – эшче төркем рәисе.

2. Мөхәммәтшина Римма Марсель кызы – эшче төркем әгъзасы.

3. Садыйкова Гөлнара Зәкәрия кызы – эшче төркем әгъзасы.

6. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча 2019 елның 15 фералендә сәгать 15.00 түбәндәге адрес буенча Баулы муниципаль районы Советы утырышлар залында ачык тыңлаулар уздырырга: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20.

7. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча Баулы шәһәр Советы депутатлары һәм гражданнарның тәкъдимнәрен, гомумиләштерергә һәм Баулы шәһәр Советы каравына чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Баулы шәһәре мэры,<br>
шәһәр Советы рәисе — Р.Х. Гатиятуллин

Баулы шәһәр
Советының 15.01.2019
елның
кабул ителгән 100 нче
санлы карарына
1нче кушымта

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында" карары
**ПРОЕКТЫ**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын яңа редакциядә кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турындагы карарны, федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен, Юстиция органына җибәрергә.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында карарны, ул дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Баулы шәһәр
Советының 15.01.2019
елның
кабул ителгән 100 нче
санлы карарына
2нче кушымта

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында" карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашуы
тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 нче йорт адресы буенча Баулы муниципаль районы Советына язма рәвештә кертелә.

Тәкъдимнәр карар басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар шәхсән яисә почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: 423930, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 (конвертта «Устав турында фикер алышу» яисә «ачык тыңлаулар» тамгасы белән).

Баулы шәһәр
Советының 15.01.2019
елның
кабул ителгән 100 нче
санлы карарына
3нче кушымта

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында" карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү
тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында" карар проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба – ачык тыңлаулар) «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

2. Ачык тыңлауларда үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән шулай ук ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясенә аны үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча язма гариза биргән район халкы да катнаша.

3. Ачык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка районның барлык кызыксынган кешеләре дә катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 1 сәгать кала башлана.

5. Ачык тыңлауларда муниципаль берәмлек Башлыгы яисә аның кушуы буенча муниципаль берәмлекнең башка вазыйфаи заты рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән башлана, ул катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне төзү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариат җитәкчесе һәм секретариатның ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы булган катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау вакыты озайтылырга мөмкин, әмма 3 минуттан да күбрәккә түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлауларның барышына тыкшынырга, аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Ачык тыңлаулар үткәргәндә тәртип саклау ачык тыңлауларда катнашуның мәҗбүри шарты булып тора.

14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамлангач, рәислек итүче, ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен, ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма формада бирелә һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм җирлек Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлауларны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы Аппараты оештыра һәм матди-техник яктан тәэмин итә.